**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Түйкә авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Түйкә авылы № 79-36 24 ноябрь 2017 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренә юбилеена бәйле рәвештә бирелә торган өстәмә гарантия турында»2017 елның 11 сентябрендәге 66-32 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренә юбилейга бәйле рәвештә бирелә торган өстәмә гарантия турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында " 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 маддәсе нигезендә,

Түйкә авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренә юбилеена бәйле рәвештә бирелә торган өстәмә гарантия турында»2017 елның 11 сентябрендәге 66-32 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренә юбилейга бәйле рәвештә бирелә торган өстәмә гарантия турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.
2. кушымтада:
2.1. 1.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле икенче - унберенче абзацлар өстәргә::
"Матди ярдәм рәвешендә өстәмә социаль һәм башка түләүләр күләменә:
- вазыйфаи оклад;
- класс чины өчен вазыйфаи окладка өстәмә;
- Еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү күләменең 1/12 өлеше;
тиешле еллар эшләгән өчен хезмәт хакына өстәмә;
- вазыйфаи окладның 50 процентыннан артмаган күләмдә айлык акчалата бүләкләү;

- муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен вазыйфаи окладка муниципаль хезмәткәр эштән азат ителгән көнгә кадәр кимендә алты ай кала билгеләнгән күләмдә айлык өстәмә;
- дәүләт сере булып торган мәгълүматлар белән эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен вазыйфаи окладның 50 процентыннан артмаган күләмдә өстәмә түләү;
- нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен вазыйфаи окладның 50 процентыннан артмаган күләмдә компенсация түләүләре;
- профильле гыйльми дәрәҗә өчен вазыйфаи окладка вазыйфаи окладның 50 процентыннан артмаган күләмдә өстәмә түләү.».
3. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә

Рәис Р.Р.Закирова